2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авылы җирлеге Иске Михайловка авылы гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫКАРАРЫ

8 декабрь 2023 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылында гражданнар җыенықарар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаиләәгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: Ирекле авылында урнашкан Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл территориясен капиталь ремонтлау һәм төзекләндерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Михайловка авылы, Мәктәп урамы, 43 йорт, Ирекле авылы, Урман урамы, 1а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин